Казан шәһәре Совет районы “Күп профильле 181 нче мәктәп”
**№ 2, октябрь, 2019 ел**

# «Күкнең җиденче катында»

**БУ САНДА:**

*Мәктәп яңалыклары*
*Безнең уңышлар*

## Мәктәп яңалыклары...

### Фән олимпиадалары

Мәктәбебездә фән олимпиадалары узды. 5-11 сыйныф укучылары төрле фәннәрдән белемнәрен сынадылар. Әлеге олимпиадалар иң әзерлекле укучыларны аерып алу өчен уздырыла.

Мәктәп олимпиадалары укучыларның гомуми белем бирү фәннәреннән Бөтенрәсәй олимпиадасының беренче этабы булып тора. Икенче этап – район олимпиадалары, өченче этап – республика олимпиадасы.

Олимпиадаларның бурычлары һәм максатлары: әзерлекле укучыларны аерып чыгару; укучыларның фәнни эшчәнлеккә кызыксынуларын арттыру.

Мәктәп этабын үтүчеләр муниципаль турда катнашачак. Ул ноябрь ае башында башлана. Укучыларыбызга уңышлар телибез!

### Укытучылар көне

Укытучылар көне 1965 нче елның 29 нчы сентябреннән, Советлар Союзыннан бирле билгеләп үтелә. 1980 нчы елдан ул октябрьнең беренче якшәмбесендә билгеләп үтелә башлады. Россиядә бу бәйрәмне 1994 елдан бирле 5 октябрьдә билгеләп үтәләр.

Бәйрәм укытучыларны котлау, аларга теләкләр язылган серле яфраклар бүләк итү белән башланды, соңыннан 5-10 сыйныф укучылары үзидарә көнен уткәрде. Максатлары - үзләрен укытучы - дублёр ролендә сынап карау.

Балалар әлеге һөнәрнең авыр икәнен, балаларга белем бирү - сабырлык һәм түземлек соравын аңладылар. Мәктәп бусагасын тәмамлап чыккач, укучыларыбыз алдында чишәргә тиешле мәсьәләләр булачак әле, ә безнең укучыларыбыз аны чишәргә һәм тиешле карарны чыгара да белергә әзерләр, дип уйлыйбыз.

Көн азагында укытучылар өчен концерт әзерләнгән иде. 2 өлештән торган концертның 1 нче өлешендә укучыларыбыз җыр-моңнарын сузып, эчтәлекле өзекләрен күрсәтсәләр, 2нче өлештә татар эстрада йолдызлары (җитәкчесе Мусин И.И) чыгыш ясадылар. Бәйрәм бик күңелле, эчтәлекле узды.

Хөрмәтле мөгаллимнәребез! Сез – безнең иң кадерлеләребез, үрнәк алырлык кешеләребез, туры юл күрсәтүчеләребез. Сез биргән белемнәр, сезнең үгет-нәсыйхәтегез безгә авыр тормышта да дөрес юлдан тайпылмыйча, гел алга барырга ярдәм итә. Һәрчак укучыларыгызның рәхмәтләренә төренеп, аларның ярдәмен тоеп яшәргә насыйп булсын! Сәламәтлек, ак бәхетләр, яңа куанычлар телибез! Бәйрәмегез белән!



## Күзгә күргәзмә

Күзне муллык, байлык фасылы дип юкка гына әйтмиләр. Шушы уңайдан мәктәбебездә әти-әниләр белән берлектә "Көзге хәзинә" дип исемләнгән күргәзмә оештырылды. Бу күргәзмәдә балаларның әти-әниләре белән бергәләп яшелчә, җиләк-җимештән эшләнгән кул эшләре урын алды.

## “Игелек кыл!”

Мәктәбебездә “Игелек кыл!” дип исемләнгән акция үткәрелде.

Онкология авырулы балалар өчен канцтовар-лар җыеп тапшырылды. Барыбыз да бер-беребезгә карата игътибарлы һәм ярдәмчел булсак иде.



## Приютка юл...

Безнең һәркайсыбыз көн саен диярлек урамнарда хуҗасыз этләрне күрә. Нинди этләр сукбайлыкка чыга? Хуҗасыз калган маэмайларны нинди язмыш көтә? Сукбай хайваннарны аулаучылардан качып котылып, приютка эләккән хайваннарның язмышы белән мәктәбебез укучылары да кызыксына...

Аларга ярдәм йөзеннән приютка азык-төлек җыеп озатылды.



## Макулатура тапшыр - агачны коткар!

Мәктәбебездә, сентябрь аенда элек-электән килүче гореф-гадәтләрне онытмыйча, сыйныфлар арасында макулатура җыю буенча ярышлар узды. Бу идеяне укучылар һәм аларның ата-аналары белән берлектә укытучылар да шунда ук хуплап алды. Укучыларның макулатура белән кызыксынуын күреп, ата-аналар, әби-бабайлар аларга үзләрендә җыелган кәгазь өемнәрен бик теләп тапшырдылар. Һәркемнең өендә актуальлеген югалткан китаплар, иске кәгазь каталоглар, күптән укылган матбугат басмалары хәйран күп булып чыкты. Нәтиҗәдә 2042 кг күләмендә икенчел кәгазь чималы җыеп алынды.

Башлангыч сыйныфлар арасында 3б сыйныфы, ә урта сыйныфлар арасында 7д сыйныфы укучылары ЭКО марафонның лидерларына әверелде. Котлыйбыз!



## Ура-а-а-а, каникуллар!

29 нчы октябрь көнне, 1 нче чиреккә нәтиҗә ясап, линейкалар узды. Уку һәм класстан тыш эшләр буенча алдынгыларга грамоталар һәм бүләкләр тапшырылды.

Укучыларыбызга укуларында уңышлар телибез!



## Котлыйбыз!



31 нче октябрь көнне Казан федераль университетының Икътисад һәм финанс институтында III Лев Толстой исемендәге Бөтен Рәсәй конференциясе булып узды.

9Б сыйныфы укучысы Нургалиева Җәмилә (укытучысы: Вәлиуллина Ә.Ф.) “Камка” дигән эзләнү эше белән 3 нче урынны яулады. Афәрин!

*******************************************

**“Ел лидеры”** ның район туры җиңүчеләре Каюмова И. (10кл), Батырова К. (5кл) республика этабында катнаштылар.




**Укучыларның Рәсәй хәрәкәте (РДШ)** берләшмәсе 4 нче ел сәләтле, эзләнүчән укучыларны җыеп, бәйгеләр уздыра.

Каюмова Ирина (10 кл.) бәйгедә катнашып, 1 нче урынны яулады. Котлыйбыз!



Грамота

награждается

За 1 место в конкурсе «Типичный активист» по Советскому району г. Казани

Председатель СДМОЮ «Молодежная Дума Советского района г.Казани» П.Д. Филатова

## “Чиксез балачак”

Халыкара "Чиксез балачак" фестиваленең муниципаль этабына йомгак ясалды. Жюри нәтиҗәләре буенча 9 класс укучылары Корчагина Яна 1 нче дәрәҗә лауреат (җит. Закамская Н.А.), Вилданова Диләрә 1 нчә дәрәҗә дипломант (җит. Закамская Н.А.), Мингараева Рената 1 нче дәрәҗә дипломант (җит. Михайлова М.М.), Морозова М. (җит. Әсхәндиярова Л.А.) диплом белән бүләкләнде .

Укучыларыбызга уңышлар телибез!

Без алар белән горурланабыз!







## “Татар егете һәм татар кызы” бәйгесе

25 нче октябрь көнне 171 нче мәктәптә “Татар егете һәм татар кызы” бәйгесенең район туры узды. Вилданова Алина(10 кл) - иң тырыш кыз, ә Вакилов Гадел(10 кл)- иң тыйнак егет номинациясе буенча диплом белән бүләкләнделәр.

Алар үзләрен төрле яктан сәләтле, камил итеп күрсәттеләр. Сүз остасы, биюче...

Менә ничек булдыралар безнең укучыларыбыз! Котлыйбыз!

## “Эшлекле иртәнге аш”

24 нче октябрь көнне Тимирясов исемендәге Казан инновация университетының менеджмент һәм инженерлык буенча бизнес факультетының фәнни эшләр буенча декан урынбасары, доцент, экономика фәннәре кандидаты Гарипова В.В белән 9 нчы сыйныф укучылары арасында очрашу булып узды.

Венера Валерьевна үзе бу ВУЗны тәмамалаган чыгарылыш студенткасы. ВУЗ ны 2003 нче елны тәмамлагач, аны актив һәм уку алдынгысы булганлыгы өчен, бу университетта калдыралар, аннары аспирантурада укуын дәвам итә. Аспирантура өчен университет тулысынча түли. Йошкар-Ола шәһәрендә диссертация яклый.

Укучылар аңа кызыксындырган сорауларын бирделәр, Гарипова В.В. аларга җавапларын бирде.

- Сез ничә яшьтә икътисад белән кызыксына башладыгыз һәм ни өчен икътисад белән?

- Минем балачактан укытучы буласым килде, чөнки әти-әниләрем укытучылар. Тик алар минем икътисади юнәлештә китүемне теләделәр. Аларга каршы килмәдем.

- Бу һөнәргә карата курку хисе булмадымы?

- Мин зур аудиториядә чыгыш ясарга курка идем, шул сәбәпле ораторлык курсларына йөри башладым. Курку хисен шулай җиңдем.

- Сез бу юнәлештән китәргә уйламадыгызмы?

- Әйе, андый вакытлар булды. Юридик белем аласым килде. Хокук фәннәреннән олимпиадаларда катнаша идем, Яр Чаллы шәһәренең 10 иң яхшы укучысы исемлегенә кердем... Әти-әниләр ул юнәлеш буенча китүемә каршы булдылар.

- Әгәр дә һөнәр сайлау алдында калсаң, үзеңә туры килгәнне ничек сайларга киңәш итәсез?

- Бу очракта сезгә профориентлашу буенча тестлар үтү ярдәм итәчәк.

- Казан инновация университетында студентларның сәләтләрен үстерүгә күп мөмкинчелекләр бармы?

- Әйе, Казан инновация университетында студентларның сәләтләрен үстерүгә күп мөмкинчелекләр бар, төрле түгәрәкләр эшләп килә (вокал, бию һ.б.).

Менә шундый рәвештә җанлы сөйләшү булып узды. Без Венера Валерьевнага уңышлар телибез!

## Октябрь аенда нинди бәйрәмнәр көтелә?

1 октябрь — Халыкара өлкәннәр көне.

1 октябрь — Халыкара торак көне.

2 октябрь — Электрон почта көне.

5 октябрь — Халыкара укытучылар көне.

9 октябрь — Бөтендөнья почта көне.

16 октябрь — Бөтендөнья азык-төлек көне.

Октябрьнең беренче дүшәмбесе — Бөтендөнья архитектура көне.

Октябрьнең беренче дүшәмбесе —Халыкара табиблар көне.

Октябрьнең беренче якшәмбесе — Халыкара хайваннар көне.

Октябрьнең беренче якшәмбесе — Авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре көне.

Октябрьнең икенче якшәмбесе — Юл хуҗалыгы хезмәткәрләре көне.

Октябрьнең өченче якшәмбесе — Азык-төлек сәнәгате хезмәткәрләре көне.

Октябрьнең соңгы якшәмбесе — Бөтенрәсәй автомобиль транспорты һәм юл хуҗалыгы хезмәткәрләре көне.


**Редакциянең адресы:**
420101, Казан шәһәре,
Тулпар урамы, 2
Тел. 89050229576
**Тираж** – 50 экз.
**Баш мөхәррир һәм дизайнер:**
Габдуллаҗанова А.Ф.
**Редколлегия әгъзалары:**
Мәхмүтова Мәдинә, Абрамова Дарья, Вәлиева Диләрә, Мельникова Аделина, Мәхмүтова Мәликә, Корчагина Яна.